ЭШ ҖИТӘРЛЕК
Республиканың социаль-икътисади торышы ни хәлдә?
> 2

БИШ ТАТАР
Заманында Алмаз Хәмзин оештырган юмор һәм сатира төркеме кызыклары
> 3

РУСЛАН КОРБАНОВ:
«Командир һәрвакыт алдан барырга тиеш»
> 4

ПОЛИГЛОТ КӨТҮЧЕ
Бишенче дистәсен ваклаган Хәмид Иранов – әнә шундый кеше
> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 165 (28938) | Чәршәмбе | 9 ноябрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

КҮРЕНМӘС ДОШМАН

СӨРЕМ ГАЗЫ НӘРСӘСЕ БЕЛӘН КУРКЫНЫЧ?

Ел башыннан Татарстанда 32 кеше сөрем газы белән агуланган. Иң аянычлысы – мондый очракларның күпчелеге беркатлылык һәм техник куркынычсызлык кагыйдәләрен санга сукмау аркасында килеп чыга. Игътибарсызлык хатасының ахыры һәрвакыт хәерле булмый. Әйтик, алдарак әйтеп киткән 32 очрак тугыз кешенең үлеменә китергән. Зыян күрүчеләр саны да шактый – 66. Алар арасында 27 бала да бар. Төссез-иссез дошманнан ничек сакланырга? Агуланган очракта, нишләргә?

Иминлеккә өстенлек

Көз-кыш айлары халык иминлеге һәм куркынычсызлыгы җәһәтеннән бик күп сорауларны өскә калкыта. Йортларга җылылык бирү башлануга, газ белән агулану куркынычы да шактый арта. Бу мәсьәләгә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та игътибар итте.

– Кызганыч, кыш айлары торак йортлардагы янгыннар саны буенча имин булмаган чорларның берсе булып тора. Тагын бер күңелсез статистика халыкның сөрем газы белән агулануына бәйле, – диде ул «шимбә киңәшмәсе»ндә. – Узган ел республикада шуңа бәйле 49 очрак теркәлгән, 16 кеше үлгән. Шуларның берсе – бала. Агымдагы елның саннары да сагайта.

Күңелсез хәлләр ишәймәсен өчен, хәстәрен алдан күрергә кирәк, билгеле. Татарстан Президенты искәрткәнчә, торак йортларда профилактик рейдлар оештыру файдалы булыр иде. «Бигрәк тә күпбалалы гаиләләр, ялгыз өлкәннәр һәм социаль яктан имин булмаганнар яшәгән йортларга игътибар итәргә кирәк. Шулай ук үз белдеге белән электр чыбыгын кисү очракларына юл куймаска, вентиляция каналларының төзеклеген тәэмин итәргә, аз керемле кешеләргә ярдәм күрсәтергә кирәк», – диде республика Президенты.

Куркыныч өн

2020 елның кышында булган вакыйга Валериянең йөрәген әле дә әрнетеп тора. Сөрем газы белән аның бәләкәй улы агулана.

– Баланы юындырдым, киендердем дә мультфильм карарга утыртып калдырдым. 10 минутлап вакыт үткәндер, аның янына чыксам, һушым китәрлек хәл күрәм: балам миңа атлап килмәкче була, әмма капчык кебек, шапылдап идәнгә ава. Торып баса, янә егыла. Кулыма алгач, аңын җуюын, күзләренең йомылуын аңладым. Ирем тизрәк «ашыгыч ярдәм» чакыртты һәм... үзе дә аңын югалтып егылды. Бу мизгелдә курыккан кадәр беркайчан да курыкканым булмагандыр! – дип искә ала Валерия. – Тагын бер мәртәбә «ашыгыч ярдәм» хезмәтенә шалтыратып, хәлне аңлаттым. Хәзер бит ирем өчен дә, улым өчен дә борчылам! Бернәрсә дә аңламыйча, күршеләргә шалтырата, нашатырь эзли башладым. Берәүдә дә юк! Үземдә дә паника, колакларыма кадәр тонды. Андый-мондый, мин дә аңымны югалтып егылсам дип, ишекләрне ачып куйдым. Ул арада «ашыгыч ярдәм» хезмәткәрләре дә килеп җитте.

Ирен тиз арада аңга китерәләр. Ә менә баланы хастаханәгә алып китәргә туры килә. Валерия сөйләвенчә, ул бала белән хастаханәдә йөргән арада, өйгә сөрем газы чыгуын ачыклыйлар. Ире авария хезмәте белән бу хәлгә ачыклык кертә. «Газны сүндерәләр, газ торбаларын алалар. Берничә көн кайнар сусыз һәм газсыз утырдык. Куркыныч өнем булды бу минем. Шуңа да хәзер бөтен кешеләргә дә газ җиһазларын тикшереп һәм тикшертеп торыгыз, дип киңәш бирәм», – ди ул.

Ахыры 2 нче биттә >



Киңәш

Михаил МАКЕЕВ, иминлек буенча танылган инструктор:
– Кеше аңын югалткан, әмма исән булуын күрсәтә торган билгеләре (йөрәк тибеше, сулыш алу) бар икән, аны яны белән әйләндерергә, баш астына нидер куярга киңәш ителә. Ята торган рәвеше аның өчен куркынычсыз һәм уңайлы булсын. Теле тамак артына китеп, сулыш алуга киртә булмасын. Юкса, кеше асфиксиядән (буылу) үлеп китәргә мөмкин. Аннан «ашыгыч ярдәм» чакыртасы. Иң мөһиме – зыян күрүче яныннан китмәскә, аны белгечләр килгәнче күзәтергә.

Акча банкка кайта

Халыкта борчылу-шомлану хисе бетеп килә – акча әкренләп кенә банкларга кире кайта. Үзәк банк башлыгы Эльвира Нәбиуллина белдергәнчә, коронавирус пандемиясе башланган чорда, быел язын һәм соңгы ай ярым эчендә кешеләрнең тынгысызлыгы арткан булган. Бу чорда банклардан күпләп акча алу күзәтелгән. «Вазгыять ачыклана төшкәч, борчылу кими һәм кешеләр дә акчасын банкка кире кайтару ягын карый. Соңгы атналарда счетлардан акча алу кимеде», – дигән ул Дәүләт Думасында ясаган чыгышында. Эльвира Нәбиуллина әйтүенчә, кешеләр башлыча акча салуга өстенлек бирә, ә бу инфляцияне акрынайта.

103 тонна ярдәм

Кичә Казаннан Луганск Халык Республикасындагы Лисичанск шәһәре халкына чираттагы гуманитар ярдәм җибәрелде. Бу юлы 103 тонна йөк белән җиде колонна машина юлга кузгалды. Гуманитар ярдәмне «Бердәм Россия» партиясенең төбәк бүлеге «Ярдәм янәшә!» хәрәкәте белән берлектә оештырды.

Җылы кием, азык-төлек, гигиена кирәк-яраклары – йөк тулы машиналарда барысы да бар. Моңа өстәп буржуйка-мичләр, шәм, генератор, газ җылыткычлары да. Гуманитар миссиягә Алексеевск, Әлки, Зәй һәм Спас районнары кушылган. «Татарстанда гуманитар ярдәм күрсәтүгә үз өлешен кертергә теләүчеләр күп булып чыкты, – диде «Ярдәм янәшә!» хәрәкәте координаторы Тимур Сафин. – Лисичанск белән элемтәдә торабыз. Без андагы кешеләрнең барлык ихтыяҗларын беләбез. Безнең бурыч – нәтиҗәле ярдәм күрсәтү».

Дару булачак

Якын араларда даруханәләрне «Амоксиклав» препараты белән тәэмин итү тәртипкә салыначак. Антибиотикка ихтыяҗ арту сәбәпләреннән берсе – сезонлы чирләрнең «баш калкытуы» һәм даруны запаска алып кую. Препарат коронавирус инфекциясенең бик нык таралган чорында күп кулланылган. Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы хәбәренә караганда, өлешчә мобилизациянең тәмамлануы, шулай ук базарга яңа җитештерүчеләрнең үтеп керүе сәбәпле, якын араларда даруханәләргә препарат китерүдәге өзеклекләр бетәчәк.

Быел беренче яртыеллыкта бу дару 5 урында җитештерелгән. Россия складларында якынча 10,5 миллион данә «Амоксиклав» исәпләнелә.

Чир тимәсен

Соңгы мәгълүматларга караганда, Татарстанда 108 кешенең коронавирус йоктыруы ачыкланган. 36 сырхауны хастаханәгә озатырга туры килгән. 8 ноябрьгә республикада чир ияртүнең барлыгы 188486 очрагы теркәлгән.

Бүгенгә республикада 185354 сырхау савыккан. Татарстанда соңгы тәүлектә чирдән үлем-китем очраклары теркәлмәгән. Федераль оператив штаб мәгълүматларына караганда, пандемия башланганнан бирле республикада 2005 кеше коронавирустан вафат булган.

Кечкенә авылны сайла

Татарстанда яшәүчеләр, югары тизлекле мобиль интернетны алданрак кертү өчен, кечкенә авылларны үзләре үк сайлап алу мөмкинлегенә ия. Тавыш бирүдә халык саны 100дән 500гә кадәрге барлык торак пунктлар катнаша. Дәүләт хезмәтләре порталында 12 ноябрьгә кадәр үз тавышыңны калдырырга мөмкин.

Россия Цифрлы үсеш, элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгы иң күп тавыш җыйган авылларга киләсе елда мобиль интернет кертәчәк. Бүгенгә 8 меңнән артыграк кеше тавыш бирүдә катнашкан инде. Тавыш бирү «Цифрлы икътисад илкүләм программасы» буенча хәл ителә. 2030 елга кадәр исәпләнгән федераль программаны «Ростелеком» гамәлгә ашыра.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Илкүләм проект

Янчыклы сабыйлар

Соңгы ун ел эчендә республикада күпбалалы гаиләләр саны 69 процентка арткан. 2012 елдан хәзерге көнгә кадәр «Ана даны» медале белән 1505 ана бүләкләнгән. Быел кертелгән яңа бүләк – «Ата-ана фидакарьлеге» медале биш ата-анага бирелгән.

Бу сөенечле яңалыклар хакында Татарстанның хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары Наталья Бутаева «Демография» илкүләм проектына багышланган чарада сөйләде.

Наталья Бутаева сүзләренә караганда, 2017 елдан Россиядә, Татарстанда сабыйлар азрак туган, әмма шул ук вакытта үлем-китем очраклары кимү күзәтелә.

– Республикада 24 меңнән артык бала туса, 30 мең 212 кеше дөнья куйган. Ковид та моңа үз өлешен кертте. Узган ел үлем-җитем күбрәк булса, быел саннар яхшырак. Былтыргы белән чагыштырганда, үлүчеләр саны 30 процентка азрак, – дип тынычландырды урынбасар.

Рәсми мәгълүматларга караганда, республикада соңгы сигез айда 24096 сабый туган. Бу узган елның гыйнвар – август айлары белән чагыштырганда, 10,5 процентка кимрәк.

Аның каравы ишле гаиләләр күбәя. Татарстанда өч һәм аннан да күбрәк бала тәрбияләүче гаиләләр арткан. Әгәр 2012 ел башына андыйлар 24,8 мең булса, быел 1 ноябрьгә әлеге күрсәткеч 42 меңгә җиткән. Сүз уңаеннан, 2006–2021 елларда 539 күпбалалы гаилә торак белән тәэмин ителгән. Гомумән алганда, 720 фатир бирелгән. Быел тагын 25 гаиләне күңелле вакыйга көтә.

Салада туган сабыйлар саны арткан. Бу күрсәткеч 2018 елда 17,5% булса, 2021 елда – 19,3%. Монда 2018 елдан авыл җирлегендә яшәүче хатын-кызларга өстәмә түләү кертү дә үзенекен иткән, дип фаразлана. Шушы вакыт эчендә 10,5 меңнән артык хатын-кыз (шуларның 1,6 меңе – 2022 ел башыннан) ярдәм чарасын алган. Билгеле булганча, республика бюджетыннан авыл җирендә яшәп, 25 яшькә кадәр беренче баласын тудырган хатын-кызларга (50 мең сум), ә 29 яшькә кадәр өченче һәм аннан күбрәк бала тудырган хатын-кызларга 100 мең сум өстәмә акчалата түләү каралган.

Журналистлар Наталья Бутаевадан: «Ни өчен авыл җирендә бирелә торган әлеге акча беренче баланы 25 яшькә кадәр табучыларга гына тиеш?» – дип тә сорады. Урынбасар аңлатканча, бу демографияне күтәрү, яшь әниләргә бала табарга этәргеч бирү өчен кирәк. «Беренчесен никадәр иртәрәк тапсалар, икенчесе дә шулкадәр тизрәк туачак. Ә инде беренче сабыен 35 яшьтә генә тудырган хатын-кызның күпбалалы ана буласына шик бар», – диде ул.

Медальләрнең әти-әниләргә бирелә торганнары да бар. «Ата-ана фидакарьлеге» медале гаиләнең, ата-аналарның абруен күтәрүне күздә тота. Ул җиде һәм аннан да күбрәк бала тәрбияләгән яки тәрбияләүче, шулай ук кимендә бер балигъ булмаган баласы булган гаиләләргә бирелә. Медаль белән бүләкләнгән гаиләдәге атага яки анага (уллыкка алган кешегә) 100 мең сум күләмендә бер тапкыр акча түләнә.

«Ана даны» медале белән бүләкләү бишенче бала өч яшькә җиткәч һәм балалар исән чакта башкарыла. Һәр балага 10 мең сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләк бу.

2020 елдан өстәмә кертелгән балалы гаиләләргә социаль ярдәм чараларын гамәлгә ашыру да дәвам итә. Алар арасында дару сатып алу өчен түләү, балалар бакчасы өчен өстәмә компенсация, яңа туган балалары булган аз керемле гаиләләргә бүләк комплектлары һәм башкалар да бар. Бу түләүләр кереме яшәү минимумыннан түбәнрәк гаиләләргә бирелә.

Сәрия МИФТАХОВА

Сүзгә-сүз

Гадел МӨБАРӘКШИН, Татарстанның хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары:

Республикада 31,4 меңнән артык инвалид эшкә урнаштырылган. Бу аларның гомуми санының 28,8 процентын тәшкил итә. Мөмкинлекләре чикләнгән кешеләргә үз эшләрен булдырырга ярдәм итү йөзеннән 145 мең сум күләмендә финанс ярдәме күрсәтелә. Әйтик, быел 9 айда 10 инвалид үз эшен ачты.

(«Татар-информ»га әңгәмәсеннән)

РОССИЯДӘ – МЕДИЦИНА ХЕЗМӘТЛӘРЕ ӨЧЕН ТҮЛӘҮ

«Росгосстрах» компаниясе оештырган сораштыру нәтиҗәләреннән күренгәнчә, Россиядә яшәүчеләр медицина хезмәтләренә күбрәк акча сарыф итә башлаган. Медицина хезмәтләре бер ел эчендә уртача 15 процентка кыйммәтләнгән.

КАЙСЫ ТАРМАКЛАРДА БӘЯ АРТКАН?

(респондентлар фикере)

Теш дәвалау	76%
Пластик хирургия	52%
Репродуктив медицина	27%
Хирургия	23%

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ДӨНЬЯ ИКЪТИСАДЫ – ДЕФОЛТ АЛДЫНДАМЫ?

Җир шарының киләчәген аның икътисады билгели. Нәкъ менә икътисадның турбулентлыгы дөньякүләм протестның үсүенә һәм кораллы конфликтларның саны һәм масштабы артуга китерә дә инде. Соңгы көннәрдә Англия банкы соңгы йөз елда күрелмәгән озак сроклы рецессия башланып килүен әйтте. Инглизләр фикеренчә, 8 квартал буе түбәнгә төшкәннән соң, икътисад яңадан югары күтәрелә, җитештерү арта башлаячак икән. Беркатлылар да инде. Бөек депрессиянең ничә ел дәвам итүен онытканнар. Соңгы йөз ел эчендә ике Бөтендөнья сугышының төп сәбәбе идарәче катлауның кризистан сугыш игълан итеп чыгарга тырышу булганын бөтенләй дә белмиләр, диярсең. Әмма Англия банкы бер нәрсәдә хаклы: моңарчы күрелмәгән базарлар депрессиясе бусаганы атлый инде.

Күп кенә аналитиклар бүгенге вазгыятьне үткән гасырның 70 нче еллары белән чагыштыра. Ул вакытта да нефть кризисы бугаздан тоткан иде. Гарәп монархияләре, 1973 елда «кара алтын» сатуны кискен киметеп, көнбатыштагыларны йомшак җәеп катыга утыртты. Ул вакытта кризиска Фәләстыйн конфликты этәргеч бирде. Ягулык дефицитыннан котылу өчен, куллануны кискен киметергә туры килде. Пол Волкер – ФРСның ул чактагы җитәкчесе – төп ставканы кискен күтәрде, җитештерү төпкә утырды, чөнки товарларга ихтыяҗ бетте, кешеләр фәкыйрьлеккә төште. Эшсезлек 11 процентка кадәр җитте. Үзәк банклар хәзер шул ысулны тагын бер тапкыр кабатлау идеясен алга сөрә. Төп ставка күпчелек илләрдә күтәрелә инде. АКШта ул үткән атнада 4 процентка җитте. Европа Үзәк банкы да ФРСтан калышмаска тырыша. Глобаль икътисадның бүген кредитлар хисабына гына яшәвен истә тотканда, җитештерү котылгысыз рәвештә кимеячәк. Кредитлар кыйммәтләнү шуңа китерә. Җитештерү кимедеме, энергия чыганакларына сорау да кими. Газ һәм нефть кризисы артка чигә. Шуннан акрынлап кризистан чыгабыз, дип уйлыйлар.

Ләкин хәзерге вазгыять җитмешенче еллардагыдан бик нык аерыла. Ул чакта СССР Көнбатышка коткару тәгәрмәче ыргытты: нефть экспортын арттырды, юан газ торбалары Европага таба сузылды. Соңыннан гарәпләр моның үчен алдылар алуын, әмма анысы – башка тарих. Үткән гасырда дәүләтләр һәм кешеләр хәзерге кадәр үк кредитка да батмаганнар иде. Алырга теләгән һәр кешегә кредит өләшеп, икътисадны җанландыру технологиясен Рейган кертеп җибәрде. «Рейганомика» дигән исем бирделәр шуңа күрә ул технологиягә. Уңга-сулга кредит өләшү бүгенге вазгыятькә китерде дә инде. Кредит кыйммәтләнгәч, болай да әҗәткә баткан кешеләр нишли? Бөләләр, әлбәттә. Кешеләр генә түгел, дәүләтләр тиңе булмаган әҗәткә батты. Дәүләтләрнең гомуми әҗәте 70 триллион долларга җитеп килә. Чагыштырыгыз: 2000 елда 18 триллион гына булган. Бу әҗәтне болай да түләп булмый инде, процентлар артканнан соң, ничек түлисең? Ягъни рейганомиканы тагын бер тапкыр гамәлгә кертеп булмый. Ике генә юл кала: я дефолт, я сугыш. Икесе бергә дә килә ала.

Россиядә

ТАТАРСТАН ШИН ИМПЕРИЯСЕНӘ ӘВЕРЕЛӘ

Россиядә рейганомика мәйданга бик соң чыкты. Кредит өләшү сәясәте бездә әле берничә ел элек кенә башланды. Ипотека кредиты бумы соңгы 4–5 елда гына көн тәртибенә куелды. Шуңа күрә японнар һәм чиннардан аермалы буларак, бездә торак куыгы алай ук кабармады. Әмма ул көчемсез милекнең чамасыз кыйммәтләнүе булып безнең кесәләргә бик каты суга. Мәгълүм вакыйгалар аркасында бөлгенлек көчәю бездә дә дефолт куркынычын тизләтә.

Әмма чит ил компанияләренең Россияне ташлап китүе сәбәпле, үзебезнең җитештерүчеләргә базарлар киңәйде. Кризис – мөмкинлекләр вакыты, дип әйтәләр бит әле. Мөмкинлекләр маршы башланды, әмма аны файдаланырга теләүчеләр бик күренми. Аңлашыла да инде: файдаланам дисәң, инвестицияләр сорый, технологик чишелешләр таләп итә. Россия бизнесы исә активлыгы белән бик куандырмый, сатып алып, яңадан сатуга гына көйләнгән.

Катлаулы вазгыятьне табышлыга әйләндерүгә омтылучылар сирәк булса да бар әле. Бөтенроссия масштабында шундыйларның берсе – «Татнефть» башкалардан аерылып чыга башлады. Россияне ташлап киткән компанияләр арасында шин җитештерүчеләр когортасы аерым бер урын алып тора. Миллионлаган данә шин җитештереп, эчке базарны тутырган чит ил компанияләре үз заводларын ябып, сатуга куйды. Фин компаниясе Nokian Tyres – шуларның берсе. Аның Ленинград өлкәсендәге Всеволожск шәһәрендәге заводы елга 16 миллион данә шин җитештерә һәм безнең «Түбән Кама Шин»нан аз гына калышып, Россия базарын тотып торучыларның берсе иде. «Татнефть» Nokian Tyres белән килешү төзеп өлгергән инде. Алыш-бирешнең гомуми суммасы 400 миллион евро тәшкил итә.

Росстат мәгълүматларына күз төшереп алыйк әле. 2021 елда Россиядә җиңел автомобильләр өчен – 47,2 миллион, йөк автомобильләре өчен 7,4 миллион шин җитештерелгән. Nokian Tyres заводын кулга төшереп бетерсә, «Татнефть» илнең шин базарын үз кулында тотачак, чөнки Түбән Камадагы елга 17 миллион данә шин җитештерүче завод та – аның милке. 33 миллион шин җитештерүче куәтнең хуҗасы булу хәзерге шартларда Татарстан компаниясен шин империясенә әвереלדерә. Ил базарын японнарның Bridgestone компаниясе, дөнья базарының 2 процентын үз кулында тотучы француз Michelin компаниясе ташлап китүен искә алсак, шин базары тулысынча диярлек татарстанлылар кулына кала. Немецларның Калугадагы Continental компаниясе августта яңадан эшкә кереште керешүен, әмма аның куәте 4 миллион шин гына. Итальяннарның Pirelli компаниясе безнең базардагы үз эшчәнлеген чикли. Дөрес, яңа автомобильләр сату быелның тугыз аенда 61 процентка кимегән кимүен. Бу – шин базарының да кысылуы дигән сүз. Әмма бүген белән генә яшәп булмый бит, киләчәккә дә карарга кирәк.

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ



tatarstan.ru

Хезмәттәшлек өчен юнәлешләр күп. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Сенегал Республикасының Россиядәге Гадәттән тыш һәм тулы вәкаләтле илчесе Жан-Батист Тиатья Тина белән очрашты. Ике як та республикалар арасындагы үсеш мөмкинлекләрен барлады.

Искәртеп үтик: илче Казанга эш сәфәре белән килде. Аның Милли китапханәдә, Иннополис шәһәрендә, Казан федераль университетында, шулай ук Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек, Татарстан Фән һәм мәгариф министрлыгында очрашулары көтелә.

Рөстәм Миңнеханов ассызыклаганча, Татарстан һәм Сенегалның хезмәттәшлеге Россия белән Сенегал арасындагы мөнәсәбәтләрне ныгытуга юнәлдерелгән. Сүз уңаеннан, быел бу хезмәттәшлеккә 60 ел тула.

Ике арадагы хезмәттәшлек нәтиҗәләрен барласак, соңгы вакытта Татарстан белән Сенегалның гуманитар өлкәдә багланышлары җанлану күзәтелә. Төрле елларда Сенегалга республикадан КамАЗ продукциясе җибәрелде. Инновация, авыл хуҗалыгы, машина төзелеше, нефть химиясе өлкәләре буенча үсеш мөмкинлекләре бар.

Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, Татарстан Сенегал белән багланышларны үстерергә тели. Соңгы вакытта элемтәләр аеруча җанланып китүен искәртте Президент. «Хезмәттәшлекне үстерү һәм тулаем Россия – Сенегал мөнәсәбәтләрен ныгыту өчен яхшы мөмкинлекләр бар», – дип ассызыклады Рөстәм Миңнеханов. Ул искә төшергәнчә, киләсе елда «Россия – Африка» халыкара саммитын оештыру күздә тотыла.

Актуаль сорау

Акча булачак

Россия Оборона министрлыгы мобилизацияләнүчеләргә тиешле акчаны алу шартларын аңлатты.

Искәртеп узыйк: октябрь уртасында Россия Президенты Владимир Путин Иминлек Советы утырышында мобилизацияләнгәннәргә акча түләү буенча проблемаларга игътибар итте. Ил башлыгы бу җәһәттән тәртип урнаштыруны сорады, акча мәсьәләсен контрольгә алырга кушты.

Оборона министрлыгы аңлатмасы:

➢ мобилизацияләнгән гражданнар өчен акчаның минималь суммасы – 195 мең сум;

➢ контракт нигезендә хәрби хезмәткә алынган мобилизацияләнүчеләргә һәм «срочник»ларга 195 мең сум күләмендә бер тапкыр акча күчереләчәк. Әлеге сумма хәрби хезмәт турында килешү төзелүгә күчәчәк;

➢ өлешчә мобилизациягә чакырылучыларга узган ай өчен акча айның 10–20 нче көннәрендә күчәчәк. Әйтик, хәрби хезмәткәр 1 октябрьдән 31 октябрьгә кадәр хезмәт иткән булса, бу чор өчен акча 10 ноябрьдән 20 ноябрьгә кадәр аралыкта күчәчәк;

➢ 195 мең сумның 158 мең сумына 13 процент керем салымы салынмаячак;

➢ акчаны хәрбинең туганнары да алырга мөмкин. Моның өчен ышанычнамә яисә өстәмә банк картасы ясатырга кирәк;

➢ акчаның күләме хәрби звание һәм вазыйфага карап аерылачак. Әйтик, взвод командиры – 225 мең сум, ә батальон командиры 243 мең сумга якын акча алачак;

➢ хәрби хезмәтнең махсус шартлары яки аерым казанышлар өчен өстәмә акча булырга мөмкин (оборона министрының 2019 елгы 727 номерлы боерыгы нигезендә);

➢ өлешчә мобилизация кысасында чакырылган хәрбиләргә акчалата ярдәм күрсәтү алданрак – 8 ноябрьдән башланачак.

Татарстан хакимияте мобилизациягә эләгүчеләрнең балаларына бер тапкыр 20 мең сум күләмендә акча бирергә вәгъдә иткән иде. Президент махсус хәрби операциягә үз теләге белән китүчеләрнең балаларына да шундый ук ярдәм күрсәтергә кушты. Татарстанның хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары Наталья Бутаева әйтүенчә, 20 мең сум акчаны алу өчен халыктан 3,5 меңләп гариза килгән. Ул искәрткәнчә, акча республиканың резерв фондыннан бүлеп бирелә. «Күпме кеше мөрәҗәгать итсә дә, түләячәкбез», – дип ышандыра Наталья Бутаева.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Илебезнең мәдәнияте һәм сәнгатен үстерүдәге өлеше, күп еллык нәтиҗәле эшчәнлеге өчен «Н.Г. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең махсус урта музыка мәктәбе укытучысы **Виват** Юлия Юрьевнага **Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә «Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Грац шәһәрендә (Австрия Республикасы) «Ворлдскиллс» стандартлары нигезендә һөнәри осталык буенча Европа чемпионатына Россия Федерациясе җыелма командасын уңышлы әзерләүне тәэмин иткән өчен «Казан медицина көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе укытучысы **Белякова** Елизавета Владимировна **Россия Федерациясе Президенты боерыгы нигезендә Россия Федерациясе Президентының Мактау грамотасы** белән бүләкләнде.

КУЛДАН ТОТЫП, ЧҮПЛӘМӘСКӘ ӨЙРӘТӘЛӘР

Табигать сагында

Быел «Эколидер» бәйгесендә оешма-предприятие, мәктәпләр, балалар бакчасы коллективлары, журналистлар гына түгел, блогерлар, фотографлар һәм видеооператорларның экологик эшләре дә бәяләнәчәк. Моның өчен 15 ноябрьгә кадәр бәйгедә катнашу турында гариза җибәрергә кирәк. Бу хакта «Татар-информ»да узган матбугат очрашуында Татарстанның экология һәм табигать ресурслары министры урынбасары Егор Тарнавский хәбәр итте.

– Экологик темаларны иң яхшы яктыртучыларны 16 декабрьдә билгеләп үтәчәкбез, – диде ул. – Әлеге бәйгедә өлкәннәр дә, балалар да катнаша ала. Республикада үсеп килүче буын табигатьне саклауда актив катнаша. Алар өчен махсус «Мәктәп экопатруле» бәйгесе дә бар.

Егор Тарнавский студентлар арасында башкарылган эшләргә дә тукталды. 2016 елдан бирле оештырылган «ЭкоЯз» бәйгесе дә табигать сагында булырга өйрәтә, ди ул. Аның сүзләренчә, авыл-шәһәрләрдә уздырылган өмәләр кешеләрне тагын да берләштерә. Быел бу чарада 755 мең кеше катнашкан.

– Шунысы сөендерә: экология акцияләрендә гаиләләре белән катнашучылар артты. «Мәктәп экопатруле» бәйгесе дә бик җанлы бара. Балалар республиканың төрле урыннарыннан чүплекләр турында хәбәр юллый. Аларны кабул иткәч, экологлар урынга чыга. Күп кенә чүплекләр әнә шул рәвешле юкка чыгарыла. Билгеле, балалар бу хәбәрләре өчен баллар ала. Күп балл җыючылар соңыннан бүләкләнә. Узган ел әлеге бәйгегә 3,2 мең гариза кабул ителгән иде, – ди Егор Тарнавский.

Экологларның максаты – балаларга кечкенәдән дөрес юл күрсәтү. Әйтик, эшләми башлаган батарейкаларны бер урынга тапшыру, калдыкларны дөрес итеп җыю – боларның барысы да киләчәк өчен эшләнә. Әгәр бала экологик тәрбияне гаиләсендә ала икән, ул инде беркайчан да кулындагы чүпне җиргә ташламаячак. Бу урында, бер районга сәфәргә чыккач, аның башлыгының ничек итеп оныкларын чүп җыярга өйрәткәнен сөйләгәне искә төште. Бу түрә машинада барганда кәнфит ашый да кәгазен кесәсенә сала икән. Моны күреп торган оныклар башта гаҗәпләнгән. Бабалары яхшылап аңлаткач, сабыйлар җиргә чүп ташларга ярамавын аңлаган. Тәрбияне чит кешеләр түгел, без үзебез бирергә тиеш. Дөрес, дәүләт оешмалары бүләк белән дә кызыктырыр, чит илгә юллама да бирер, әмма чүпләмәү гадәте канда булырга тиеш.

Дәүләт оешмалары дигәннән, алар әллә ниләр уйлап таба. Тиздән Казанда экологик диктант язачаклар. Узган ел аны язуда иң күп кеше бездән катнашкан икән. 4,6 мең кеше диктантны дөрес язган. Ул 11 ноябрьдә иртәнге сәгать 10.00да узачак. Бөтен Россия буенча экологик диктант 27 ноябрьгә кадәр узар дип көтелә.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Күренмәс дошман

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Сакланганны саклар

Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан буенча баш идарәсендә аңлатуларынча, сөрем газының төп чыганаклары – төзек булмаган газ, утын мичләре һәм башка газ приборлары, бассейннардагы су җылыткычлары, машинаның газ чыгаручы двигательләре. Иссез-төссез дошман мичләрдәге ярыклардан тарала. Төтен чыга торган торбалар тыгылу да, мич торбаларында җилдән саклагычлар яисә вентиляция тиешле дәрәҗәдә булмау да куркыныч хәлләрнең сәбәпчесе булырга мөмкин.

Сөрем газы бик мәкерле. Аның исе, төсе юк. Шуның белән кеше өчен куркыныч та. Агулануны ничек аңларга соң?

Агулану дәрәҗәсенә карап, аның билгеләре дә аерыла. Әйтик, җиңелчә агулану очрагында кеше канында сөрем газының күләме 0,07 проценттан артмый. Баш әйләнү, косасы килү кебек билгеләр күзәтелә. Ишек-тәрәзәләрне ачу, зыян күрүчеләрне урамга чыгару кебек гамәлләрне башкару мөһим. Әлбәттә, табиб чакырту!

Уртача дәрәҗәдә агулануда аңны югалту, галлюцинация, югары кан басымы, пульсның ешаюы күзәтелә. Бу очракта зыян күрүчегә, һавага алып чыгу гына түгел, коткаручы һәм табиблар ярдәме дә кирәк. Андый очракта кешене кислород баллонына тоташтыралар.

Агулану бик җитди булганда, кандагы газ күләме 1,2 проценттан артып китә. Сулыш алу кыенлаша, кан басымы түбәнәя, кеше агарып китә, тартыша башлый. Кешегә комага китү яисә үлем куркынычы яный. Бу очракта кешене кичекмәстән хастаханәгә салырга кирәк.

Белгечләр, фаҗигагә китерерлек очраклар булмасын өчен, кайбер кагыйдәләрне истә тотарга киңәш итә. Иң элек, газ җиһазларының, төтен һәм вентиляция каналларының торышын даими контрольдә тотарга, җиһазларның тарту көчен тикшереп торырга. Газ җиһазларында башкарасы эшләрне төгәлләгәннән соң, краннарны ябарга. Йортларда һәм фатирларда төтен йөри торган юлларны япмау хәерле. Газ янган җирдә һава йөрергә тиеш. Ул-бу булуга, кичекмәстән «04» телефонына шалтыратырга, газчылар ярдәменнән файдаланырга киңәш ителә.

БЕР КАРАНЫҢ БЕР АГЫ

Чикләүләр тагын биш ел дәвам итсә, икътисадны тулысынча торгызып бетерергә мөмкин. Хөкүмәт йортында узган брифингта Татарстанның сәнәгать һәм сәүдә министры Олег Коробченко шулай дип белдерде. Министр фикеренчә, икътисадта катлаулы вазгыять хөкем сөрсә дә, Татарстан сәнәгате үсә бирә.

– Бүген бездә сәнәгать үсеше индексы 109,8 процент тәшкил итә. Бу – безнең икътисад, кайбер төр комплектлаучы детальләргә кытлык кичерүгә карамастан, үсә башлады дигән сүз. Көндәшлек юк икән, димәк, сәнәгать үсеше өчен менә дигән чор җиткән, – ди Олег Коробченко.

Дөрес, республикада торгынлык кичергән юнәлешләр дә бар анысы. Әйтик, әлегә Татарстанда җиңел машина һәм резин-техник эшләнмәләр җитештерү аксый. Әмма министр моны вакытлы күренеш дип саный. Ник дигәндә, Алабуга һәм Чаллыдагы заводлар тиздән бу эшкә керешәчәк. Олег Коробченко Тольяттиның Татарстанда җитештерелгән шиннарны кулланучы «АвтоВАЗ» оешмасы эшчәнлеге яңаруга да зур өметләр баглавын яшермәде.

– Аннары безнең эшләр тагын да алга китәчәк. Кайбер кыенлыклар булса да, нефть табу, нефть химиясе, нефть эшкәртү, машина, судно төзелеше, авиатөзелеш тармаклары – үсештә. Бу уңайдан борчылырга кирәкми. Чикләүләр тагын биш ел дәвам итсә, икътисадны тулысынча торгызып бетерер идек, – ди министр.

Олег Коробченко фикеренчә, чит илләр белән мөнәсәбәтләрнең киеренке булуы да вакытлыча, 2–3 елдан ике арадагы күпер кабат яңарачак. Канада, Литва, Франция, Финляндия, Чехия кебек илләрдә Татарстан Сәүдә-сәнәгать палатасының вәкиллекләре әле дә эшләвен дәвам иттерә.

«Без, әлеге вәкиллекләрне ябып, аларны чит илләр белән мөнәсәбәтләр уңайлангач кына ачып, шактый акчаны янга калдыра алабыз. Әмма мөнәсәбәтләрне өр-яңадан башлау бик кыен булачак. Шуңа күрә бу вәкиллекләрнең элеккечә үк эшләп торуы яхшырак. Икътисад барыбер җиңәчәк, 2–3 елдан мөнәсәбәтләрне яңадан җайга салырга кирәк булачак, – диде министр.

Коробченко сүзләренә караганда, республиканың дус булмаган илләрдәге вәкиллекләрендә хезмәт куючыларның эше бүген бермә-бер арткан. Әйтик, Франциядәге вәкиллекләрдә эшләүчеләр хәзер Төньяк Африканың халкы француз телендә аралашкан илләре, шул исәптән Сенегал белән элемтәләрне җайга салырга ярдәм итә икән. «Үзәк Европа вәкиллеге хезмәткәрләре башка илләрдә алмаш табып булмаган товарларны импортлау белән шөгыльләнә. Күрүебезчә, дус булмаган илләрдәге Татарстан вәкилләренең эше баштан ашкан», – ди министр.

Шул рәвешле, Татарстанның икътисади яктан авыр 1990 нчы елларда барлыкка килгән Сәүдә-сәнәгать палатасы бүгенге катлаулы вазгыятьтә дә уңышлы гына эшләвен дәвам иттерә. Аның җитәкчесе Шамил Агиев сүзләренә караганда, Палата утыз елдан бирле республика эшмәкәрләре мәнфәгатьләрен кайгырта. Хезмәттәшлек күперен ныгыту максатыннан, чит илләргә эшлекле сәфәрләр оештырыла. Узган елның 1 октябрендә Татарстанның Сәүдә-сәнәгать палатасында бу максаттан Халыкара хезмәттәшлек бүлеге дә булдырылган.



Илдар Мөхәммәтҗанов

– Быелгы ун айда безгә эшмәкәрләрдән 4952 мөрәҗәгать килеп иреште. Гыйнвар – октябрь айларында барлыгы 484 очрашу оештырылды. Безгә кушылган эшмәкәрләр саны елдан-ел арта бара. Татарстандагы 88 оешма Сәүдә-сәнәгать палатасы әгъзасына әверелде. Бу эшмәкәрләрнең безгә ышануы хакында сөйли, – ди Шамил Агиев.

Ел башыннан бирле Палатаның сертификация бүлеге тарафыннан оешмаларга товар үткәрү өчен 8,1 меңнән артык сертификат тапшырылган. Бу документ Ерак һәм Якын Көнчыгыш илләренә товар чыгару өчен кирәк. «Татарстанның Сәүдә-сәнәгать палатасы Россия Дәүләт Думасы һәм Татарстан Дәүләт Советы белән дә актив эшли. Эшмәкәрлек субъектларының инвестицион активлыгын тәэмин итү – безнең төп максат», – ди Шамил Агиев.

Утырышта мобилизациягә эләккән эшмәкәрләргә каралган ярдәм чаралары турында да сүз булды. Олег Коробченко сүзләренә караганда, әлегә алар җитәрлек дәрәҗәдә түгел. Килеп туган вазгыятьнең эшмәкәрлек тармагы өчен дә зур сынау булуын яшерми ул.

– Хәрби комиссариат вәкилләре килеп, кайбер белгечләрнең Ватан алдындагы бурычын үтәргә китәчәген хәбәр иткәч, оешманың эшчәнлеге тукталырга тиеш иде кебек. Әмма бу хәлдән дә чыгу юлын таптык. Кешеләр җыеп, оешмаларның өзлексез эшләвен тәэмин иттек, – ди Коробченко.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

САЯРА ИСЕМЕНДӘГЕ...

Күптән түгел Арча районының Иске Ашыт авылында зур вакыйга булды. Бәлки, ул авыл, район өчен генә зур вакыйгадыр һәм аның турында зурдан кубып язарга кирәк тә түгелдер. Авыл мәдәният йортына Саяра Фәттерахманова исемен бирделәр. Арча халкы Саяра апаның кем икәнен белә, ә менә читтән килгән кеше һичшиксез бу исем белән кызыксыначак, «Саяра – кем соң ул?» – дип сорашачак.

Арчада күренекле шәхесләрнең исемен йөртүче мәдәният йортлары бар. Шуларның берсе – Утар-Атыда, татар театрына нигез салучыларның берсе Нәгыймә Таҗдарованың туган авылында. Аңа әле 1939 елда ук ТАССРның халык, 1940 елда РСФСРның атказанган артисты исеме бирелгән. Кыскасы, исеме телдән-телгә күчеп сөйләнерлек шәхес ул. Ә Саяра апа исә зур исемнәр алган профессиональ артистка түгел.

1947 елда Саяраны кырык терәүле авыл клубына мөдир итеп куялар. Сугыштан соңгы елларның нинди булганын үзебез күрмәсәк тә, ишетеп, укып беләбез. Илдә – ачлык-ялангачлык. Кешедә иң элек тамак кайгысы. Менә шул заманнарда 19 яшьлек Саяра кешенең күңелен, рухын күтәрергә тиеш була. Аңа: «Эч пошырып йөрмә әле, уйнап-биеп йөрер чакмыни?!» – дип әйтүчеләр дә табылган. Әмма тормыш дәвам итәргә тиеш бит. Саяра да авыл халкын әнә шуңа ышандырырга тиеш була.

Мәдәният йортына исем бирелгән көнне мин Иске Ашытка барып килгән идем. Саяра апаның улы, Татарстанның халык артисты Фердинанд Фәтхи белән очрашып-сөйләшеп утыру өчен махсус бардым. Чөнки аның ярты гомере Иске Ашытта уза. Әнисе эшләгән клубта режиссер да ул. Акчасына кызыгып урнашмаган, аларның нәселенә клуб җене кагылган. Саяра апа, пенсиягә чыккач, җанына тынычлык таба алмый алҗый. «Клубтан аерылуны бик авыр кичерде. Моны өйдәгеләр күреп-сизеп торды һәм: «Хет клубтан бер әйләнеп төш!» – дип әйтәләр иде», – ди Фердинанд. Һәм клубка менә Саяра апа, кешеләр белән аралашу, клубның һавасы ук аңа шифа бирә. Нишлисең, чын фанатик инде менә.

Саяра апага 70 яшь тулу уңаеннан клубта бәйрәм уздыралар. Бәйрәмгә мәшһүребез Илһам Шакиров та кайта. Аның сөйләгәннәрен Фердинанд бүген дә сүзен-сүзгә диярлек хәтерли әле. Илһам ага: «Ходай биргән таланты белән сәхнә тотучы хыялыйлар булган кебек, Саяра апа кебек үз эшенең хыялыйлары да була», – дигән.

Шундый хыялый булмаса, Саяра апа сәхнәдә җырламас, биемәс, үзе театр оештырып, спектакльләрдә төп рольләрне башкармас иде. Театрга, атаклы режиссер Шириаздан Сарымсаков тәкъдиме белән «халык» исеме бирелә. Иске Ашыт халык театры спектакльләре турында игъланнар чыкса, «Саяра уйный микән?» – дип сораулар гадәти хәлгә әйләнә.

Авыл клубында фольклор ансамбле дә оештыра Саяра апа. Бер елны боларны Кәрим Тинчурин театрына Республика фольклор фестиваленең йомгаклау концертына чакыралар. Юлда автобуслары ватыла. Берәү булса, бәлки, кире борылыр иде. Шул вакыт Саяра апа якында гына электричка тукталышы барлыгын шәйләп ала. Утызлап артист, «Аулак өй» күренешен күрсәтү өчен әзерләнгән, йон эрләү кабасы, комган-чиләкләр, гармуннар күтәреп, тукталышка килеп җитәләр. Электричкада «Компрессорлар заводы» тукталышына хәтле килеп, троллейбуска күчеп утыралар. Якын-тирәдәге халыкның бу тамашага ничек гаҗәпләнгәнен күз алдына китерәсездер инде. Бөтен бутафорияне күтәреп, җырлый-җырлый троллейбустан төшә дә Тинчурин театры бинасына җырлый-җырлый кереп тә китә Иске Ашыт әртистләре. Боларны, аларның җитәкчеләре Саяра апаны хыялый дими, кем дисең инде?!

Әнисенә ияреп, Фердинанд та балачактан ук клубка йөри башлый. Концертларда җырлый, спектакльләрдә уйный, күрше-тирә районнарга һәм авылларга гастрольләргә йөрергә дә туры килә аңа. «Өйгә төнге икеләрдә-өчләрдә кайткан чаклар да еш була иде. Әмма гаиләдә әнигә: «Нигә мондый һөнәр сайладың?» – дип әйтүче булмады. Әтием Рафаэль гастрольләргә кайчак үзе алып барды, алып кайтты. Шофер иде ул. Ә әтинең әнисе Галия әби: «Үз эшен яратып эшли бит, эшләсен!» – дип кенә әйтә иде», – ди Фердинанд.

Әлбәттә, клуб мөдире хезмәтен эшкә санамаучылар да булган. Элек клуб мөдиренең шактый эше колхоз рәисенең үзешчән сәнгатькә нинди мөнәсәбәттә булуына бәйле иде. Клубка берәр кирәк-ярак юнәтәсе, концерт-спектакль белән каядыр барасы булса, мәсьәләне бары тик председатель хәл итә. Саяра апа да иртәнге нәрәдкә еш төшә торган булган. Нәрәд башланырга, гадәттә, берәр сәгать алдан, иртәнге дүртләрдә килә икән бу. Колхоз рәисе Сәет Галәвиев аңа һәрвакыт: «Саяра, синең өеңдә бер дә эшең юк мәллә?» – ди торган булган. Саяра апа да: «Минем эшем шул инде, иптәш Галәвиев, сездән клуб өчен нидер сорау. Моңа хәтле сүземне аяк астына салып таптамадыгыз, бу юлы да ярдәм итәрсездер бит», – дип, рәисне тыңлата килгән.

Әлбәттә, һаман кул сузып, нидер сорап йөрмәгән Саяра апа. Дөрес, баштарак, мәсәлән, спектакльләр өчен авыл кешеләреннән киемнәр сорап тора торган булганнар. Соңыннан концерт-спектакль куйган акчага үзләре тектерә башлаганнар. Фердинанд: «Ул күлмәкләр бик кадерле иде, берәр кеше урламасын тагын дип, концерт-спектакльләрдән соң әни аларны өйгә алып кайтып куя иде», – ди.

Мин аны тыңлап утырам да сокланып куям. Әнисенең бөтен хезмәтен күреп-белеп, үзе дә клуб эшендә катнашып үскән ул. Әнисенең СССР Мәдәният министрлыгы тарафыннан күкрәк билгесе белән бүләкләнүен дә, Арчаның почетлы гражданины булуын да, 1985 елның 9 февралендә Татарстан хатын-кызлары съездында катнашуын да көне-сәгатен әйтеп дигәндәй сөйли. Саяра апа әле Иске Ашытта курчак театры да оештырган булган икән. Казан курчак театрына барып, иске курчаклар да сорап йөргән иде, бирмәгәннәр, үзебезгә бик кадерле, дигәннәр.

«Шуннан соң ниндидер журналда Мәскәүдә курчаклар ясаулары турында игълан күреп, заказ биреп, курчаклар кайтарттты. Шулай итеп Иске Ашытта курчак театры да эшли башлады. Спектакль белән күрше авылларга да йөрдек, клублар шыгрым тула иде», – ди Фердинанд.

Замана үзгәрешләре авылларны да шактый талкыды. Клуб эшчәнлеге дә кайчак клубны ачып ябарга гына кайтып кала. Әмма, берәүләр зарланса, икенчеләр эшли әле. Мәдәният учагын гөрләтеп тоту Иске Ашытта да бик җиңел түгел, авылларда халык саны кими. Быел тугызъеллык мәктәпне өч авылга 48 бала тәмамлаган. Искә төшкәч, әйтеп куйыйм әле: 1966 нчы елда безнең Субаш-Аты урта мәктәбен генә дә йөзгә якын бала тәмамлаган иде. Авылда «Саяралар» да юк шул хәзер. Ярый әле Иске Ашытта Саяра Гыйбадулла кызы Фәттерахманованың исемен мәңгеләштерделәр, халык күңелендә аның турында матур истәлекләр яши. Ә аның туганы, ягъни Саяра апаның энесенең кызы Гөлсинә Халикова – клуб мөдире. Улы Фердинанд быел режиссер буларак, Галимҗан Ибраһимов повесте буенча эшләнгән «Татар хатыны ниләр күрми» спектаклен чыгарган. Җитмәгән артистларны күрше авыллардан чакырганнар. Берәүләр: «Бетәбез!» – ди, икенчеләр бетмәс өчен тырыша. Тормыш шулай бара инде ул. Ә якташларым «икенчеләр»гә керә, чөнки алар икенчерәк шул.

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

БИШ ТАТАР

Мин кулыма китап алам

Бу исемне күргәч тә, баш кашып куйдыгызмы? Исегезгә төштеме? Шул инде, шул. Заманында Алмаз Хәмзин оештырган юмор һәм сатира төркеме турында сүз бара. Сүз башында ук исемнәрен дә барлап куйыйк: Равил Шәрәфиев, Рәшит Шамкаев, Хәлим Җәләлов, Рәшит Сабиров һәм Алмаз үзе.

«Татар-информ»

Татарстан китап нәшриятында нәшер ителгән бу китапның «Китап-clab» әдәби ресторанында үткәрелгән тәкъдим итү кичәсенә үзе генә килгән иде ул. Җыелган халык, әлбәттә инде, бүген исән-сау булган тагын ике юморчыны көткән иде. Равил Шәрәфиевнең ниндидер сәбәпләре килеп чыккан, ә Рәшит Сабиров Яшел Үзән районындагы Бәчек дип аталган туган авылында әле һаман да ял итепме, эшләпме ята, ди.

Алмаз Хәмзин, ялгызы гына булса да, аптырап кала торганнардан түгел анысы. Аны заманында: «Без кылана гына беләбез, син эшләрсең», – дип, иптәшләре төркем җитәкчесе итеп тә юкка гына сайламаганнар бит инде. Аннан килеп, китапның авторы да – үзе. Бер сулыштан күңелендәген дә сөйләп ташлады, тамашачыларны җырлары белән дә «сыйлады».

– «Биш татар» төркеме күктә атылган яшен кебек булды ул. Янып, ялкынланып яшәдек. Бик бирелеп эшләдек, үзебезчә халыкка, әдәбиятка хезмәт иттек. Менә инде арабыздан икебез – Рәшит Шамкай белән Хәлим Җәләй китеп тә барды. Без бик озак, матур аралаштык бит. Кайларга гына бармадык та, кайларда гына чыгыш ясамадык. Нинди генә халәттә булсалар да, алар халык алдына, сәхнәгә чыктылар, уйнадылар. Гомерләрен халыкка хезмәт итүгә багышладылар. Бергә йөргән вакытта мин бу шәхесләрне әллә нихәтле өйрәндем кебек. Димәк, аларны миннән дә күбрәк белгән кеше юктыр дигән фикергә килдем. Сөйләгән сүзләрен, гыйбрәтле хәлләрне дә тарихка кертеп калдырырга булдым, – дип сүз башлады ул.

Китапның үзенчәлеге нидә? Алмаз Хәмзин бу сорауга да җавап бирде.

– Шәхесләр турында китаплар күп чыга. Күбесе фотоальбом рәвешендә. Анда гадәттә кешенең эшчәнлеге күрсәтелә, фотолар куела, мактау сүзләре языла. Мин уйландым-уйландым да башка юлдан киттем. Аларның кичерешләрен, тормышта ни күргәннәрен бәян итәргә булдым. «Ничек шулай абруйлы кеше булып җитешкәннәр?» дигән сорауга җавап бирергә тырыштым. Шуңа күрә повесть жанрына туры китереп яздым.

Әле китап язу турындагы уй башына килгәнче үк Рәшит Шамкай турында повесть язарга алына. Әсәр «Казан утлары» журналында басылып чыга. Ни өчен бу эш нәкъ менә Шамкайдан башланган икән?

– Әзһәр Шакиров әйтмешли, без Шамкайны гел типкәләп йөрттек. Шамкай-шамакай дип әйтүчеләр дә булды. Бераз үпкәсе дә калгандыр инде. Югыйсә ул бит – гомер буена Камал театрында уйнаячакмын, дип яшәгән кеше. Повестьны укыгач, Әзһәр ага рәхмәт әйтеп кулымны кысты, син Шамкайга һәйкәл куйгансың, диде. Алай ук та түгелдер инде ул. Әмма ничектер шул сүзләр күңелемне кузгатып җибәрде. Төркемдә башкалар да бар бит әле, димәк, алар турында да язарга кирәк, дип уйладым.

Равил абый Шәрәфиев – бик үзенчәлекле кеше. Халык аны күбрәк бөек артист буларак белә. Әмма бу китапта мин бер серне ачам: Шәрәфи ул – сәясәтче. Җәмгыять нинди халәттә, гади кешеләр, түрәләр ничек яши? Ул гел шундый сорауларга җавап табарга тырышып, анализ ясап йөри. Иң кызыгы: белмәгән нәрсәсе юк аның. Теләсә кем белән теләсә нинди темага фәлсәфә кора ала. Китап укучыларга Шәрәфинең нәкъ менә шул ягын күрсәтергә тырыштым.

Хәлим Җәләй турында язу кыенрак булды. Артыннан байтак йөрдем. Һич ризалашмый. Кирәкме икән инде ул, Алмаз, ди. Ә мин бер юнәлеш алдым бит инде. Артка чигенү турында уйламыйм да. Хәлим абый үзе дә язучы булгач, куркыта да. Мин язуын язармын, аңа ошармы икән, дигән уйлар килә башка. Шулай да бер җаен таптым. Бакчалары бик ерак иде аларның. Көзге көннәр. Телефоннан номерын җыйдым да: «Бакчага барасыгыз юкмы соң, Хәлим абый?» – дип сорадым. «Флүрә, Алмаз бакчага чакыра, барасыңмы-юкмы?» – дип, хатынына эндәште бу. Ерактан гына: «Бил авырта бит», – дигән тавыш ишетелде. Хәлим абый артык иркәләнергә ирек бирмәде: «Барасың», – диде. Ул ара булмый, чиләк тәгәрәгән тавыш ишетелеп китте. «Ремонттан соң такталар калган иде. Бик мишәйт итәләр. Төяп китәргә җай булмасмы икән?» – дип, Хәлим абый яңадан минем белән сөйләшә башлады. «Алып кайтасыңмы соң?» – дип сорарга да онытмады. Китеп бардык шулай. Бакчасы ташландык хәлдә. Яз көне суган утырткан булганнар. Тагын укроп тишелеп чыккан. «Булышыймы азрак, бакча эше сагындырды. Минем дә бакча бар иде бит. Хәзер юк инде», – дигән булам. «Юк-юк, – дигән булалар миңа. – Әнә соң өлгерә торган кура җиләкләре. Чәй эчеп кенә утыр». Җир каткан. Суганны эзләп табам, тартып карыйм: я сабагы өзелеп чыга, я чыкканының кабыгы куба. Аптырагач, көрәк белән актарып чыктым. Шундый матур көн иде ул. Җил булмагач, суган әчесенә елап утырам шулай. Ниһаять, Хәлим ага яныма килеп елышты. «Суган утау ул – сәхнәгә чыгып сөйләнү генә түгел шул», – ди. Шуннан сүз ялганып китте бит. Рәхәтләнеп сөйләштек.

Ә Рәшит Сабировны беләсез инде. Мин аның турында язылган бүлекнең исемен «Бердәнбер» дип куйдым, чөнки нәфис сүз өлкәсендә Рәшит кебек булдыручы беркем дә юк. Театр сәхнәсендә бар әле ул, ә менә алып баручылар арасында юк. Профессиональ рәвештә озак еллар буена хөкүмәт концертларын алып барган кеше бит ул. Туры сүзле. Кемнең өстә, кемнең аста булуын карап тормый. Бер караганда, алай ук итәргә дә кирәк булмагандыр аңа. Әмма Рәшит ул хакта уйлап та карамагандыр, мөгаен. Аның турында язу авыр. Кайбер әйберләр белән килешмәскә, үпкәләргә дә мөмкин. Ләкин аның да җаен таптык.

Бишенчесе – үзем. «Рәхмәт сиңа, музфак» дип яздым. Шуны күргәч, авылдашым, сабакташым, язучы Разил Вәлиев тә уйга калды. «Менә без дә укыдык бит инде. Беребез дә бу темага алынмадык. Укытучыларыбыз турында язмадык. Профессорларга зур хөрмәт белән язган әсәрләребез юк», – диде. Чыннан да, шәхесләр турында язып, бу юнәлешне чагылдырган язучыларыбыз сирәк. Мин инде оста язганмындыр дип әйтмим. Әмма шунысын беләм: шәхесләр турында язарга, бу юнәлешне күтәрергә кирәк. Яшерен-батырын түгел, кайвакыт мактау сүзләре дә ишетәсе килә. «Үсендерү» дигән нәрсә оптимистик рух, яңа әсәрләр иҗат итәргә стимул бирә бит ул.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Апас районы Чирмешән авылында туып-үскән, хәзерге вакытта «Татарстан – Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе хезмәткәре, Казандагы Апас якташлык җәмгыяте әгъзасы **Алсу Фәһим кызы ӘСХӘДУЛЛИНА**ның күркәм юбилее.

Хөрмәтле якташыбыз Алсу ханым!
Бәйрәмең матур көннәр, изге хәбәрләр, шатлыклы яңалыклар гына алып килсен. Бүгенге шат, сәламәт, бәхетле елмаюың сине беркайчан да ташламасын. Һәрчак шулай саф күңелле сердәшче, тугры ярдәмче, үз һөнәрен яхшы белгән хезмәт өлгесе булып озак еллар яшәвеңне телибез. Сәламәтлек, җан-тән тынычлыгы һәм бәхет сиңа ихлас күңелдән. Сиңа алга таба да иҗади уңышлар, саулык-сәламәтлек, гаилә бәхете, озын гомер теләп, хөрмәт белән, *Казандагы Апас якташлык җәмгыяте әгъзалары*

Яшәргә өйрәнәбез

РАВИЛ КУЗЮРОВ:

«Һәр агач исәптә булачак»

Республикада Цифрлаштыру елы дәвам итә. Күп кенә кәгазь эшләре күптән электронлашты инде. Кешеләр үзләренә кирәкле хезмәтне өйләреннән чыкмыйча гына да башкара ала хәзер. Моның өчен бары кул астында компьютер, смартфон һәм интернетың булу кирәк. Урман хуҗалыгы да электронлашып килә. Урманчылар нинди эшләр башкарган? Цифрлаштыру эшләре ничек бара?

Без әнә шул хакта Татарстанның урман хуҗалыгы министры Равил КУЗЮРОВтан сораштык.

:: Урманны цифрлаштыру ничек бара?

– Урманнарны цифрлаштыру 3 ел дәвам итә инде. Бу Татарстан Хөкүмәте, Татарстан Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы һәм Иннополис университеты ярдәме белән тормышка ашырыла башлады. Беренчедән, без Татарстанның урман фондының мәгълүмати системасын булдырдык. Бу порталда урман фонды турындагы барлык мәгълүмат тупланды. Әлеге системаны ачу белән, урман хуҗалыгы белгече урманчылыкларның чиген, биредә ниләр үскәнен, күпме агач запасы барлыгын күрә. Бу эш кайбер мәйданнарның урман фондына карау-карамавын ачыклау өчен дә кирәк.

Икенчедән, урманнарны без хәзер дистанцион рәвештә тә күзәтә алачакбыз. Бу система урман байлыкларын исәптә тотуны автомат рәвештә башкара. Шулай ук рөхсәтсез киселгән мәйданнарны, янган җирләрне, авыру агачларны, урман эчендә законсыз төзелгән корылмаларны да ачыкларга ярдәм итә.

Өченчедән, безнең белгечләр урман комплексының исәп системасын алып бара башлады. Цифрлаштыру документларны тәртипкә салырга да ярдәм итә. Урманга кагылышлы документлар әзерләү, хисап тоту, түләүләр, үзагачны исәптә тоту һәм аңа бәйле сату-алу эшләре, документлар алышу шушы система аша үтә.

:: Социаль әһәмияткә ия документлар электрон вариантка күчеп беттеме әле?

– Быел нәкъ менә шушы эшне башкардык. Урман хуҗалыгында күрсәтелә торган 13 хезмәтне электронлаштырдык. Алар арасында җир мәйданнарын аукцион аша арендага бирү, урман җирләрен бушлай куллануга тапшыру, вакытлыча файдалану, үсентеләрне сату-алу килешүләре, урманнардан файдаланган өчен декларацияләр кабул итү, дәүләт карамагында булган җирдән файдаланган өчен рөхсәт бирү, урманнарны яңарту эшләре өчен килешүләр төзү һәм башкалар бар. Әлеге хезмәтләрдән файдалану өчен Россия яки Татарстанның Дәүләт хезмәтләре порталы аша гариза бирергә була. Әмма теләгән кешеләр гаризаларны кәгазьдә тапшыра ала. Электронлашу дигәч тә, моны бөтен кешегә дә мәҗбүри эшләргә димәгән. Элеккечә өйрәнгән кеше үзенчә эшли. Статистикага күз салсак, Урман хуҗалыгы министрлыгына килгән 11,4 мең гаризаның 7,9 меңе электрон рәвештә башкарылган. Интернет аша эшләү исә бизнес вәкилләренә бик уңай. Ул аларның эшен җиңеләйтә, вакытын янга калдыра. Без әле ел ахырына кадәр электрон рәвештәге мөрәҗәгатьләр артыр дип көтәбез.

:: Урман хуҗалыгын цифрлаштыру буенча тагын нинди эшләр башкарыла?

– Без урман фондын тулаем бер урынга җыярга тиеш. Моның өчен республиканың һәр урманчылыгына интернет кертеләчәк. Бу эшне «Таттелеком» оешмасы башкара. Интернетка тоташтыру эшләре 45 урында дәвам итә, алар 1 ноябрьдә тәмамланачак. Хәзерге вакытта квадрокоптерлар алу эшләре башкарыла. Министрлыкка компьютерлар, ноутбуклар, планшетлар да алына. Моның өчен безгә республика бюджетыннан 81,5 миллион сум акча бүлеп бирелде.

Җирләрне урман фондына кертү җиңел эш түгел. Юридик яктан да бар нәрсә тәртиптә булырга тиеш. Безнең алда урманнарның исәбен алу бурычы гына түгел, шушы проект аша аларны саклау, арттыру да тора. Цифрлы база мәйданнарны планлаштыру, кайбер проект эшләрен башкару, җир мәйданнарын килештерү, автомобиль юлларын төзү, экологик эзләнүләр өчен дә кирәк булачак.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

vk.com

Утеряно приложение к диплому ВСВ 0481600 (регистрационный номер 1280/04 от 17 июня 2004 года), выданному на имя Михайловой Валентины Петровны Казанским государственным педагогическим университетом.

Утерян диплом, выданный ГАПОУ «Казанский медицинский колледж» в 2017 году на имя Нотфуллина Булата Фанисовича.

БЕЗДӘН СЕЗГӘ – 3 БҮЛӘК

1 **ЯЗЫЛ!**
2023 елның
беренче яртыеллыгына
«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»
газетасына язып

2 **КВИТАНЦИЯ КҮЧЕРМӘСЕН БЕЗГӘ ҖИБӘР!**

89179270040
info@vatantat.ru
420097, Казан шәһәре,
Академия урамы, 2 нче йорт.

3 **БҮЛӘККӘ**
1. Суыткыч.
2. Микродулкынлы мич.
3. Мультиварка.

П2435
җомга саны
512 сум 70 тиен

П2409
атнага дүрт тапкыр чыга
1143 сум 96 тиен

Акция 2022 елның 26 октябреннән башлап 2023 елның 20 гыйнварына кадәр дәвам итә.
Акцияне оештыручы ТР ДБУ «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
Тулырак: vatantat.ru

16+

реклама

ЭШТӘ ТЫРЫШ, СӘХНӘДӘ – УТ

«Татар-информ»

Иҗатка тартылган яшьләрне берләштерә, сәхнәдә яңа йолдызлар кабыза. 7 ноябрьдә Казанда «Наше время – Безнең заман» X эшче яшьләр иҗаты ачык республика телевизион фестиваленең йомгаклау гала-концерты узды. Чарада Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та катнашты.

«Безнең заман» фестивале республикабызның эшче яшьләрен кабат «Пирамида» сәхнәсенә җыйды. Ноябрь аеның матур традициясенә әверелгән әлеге чарада быел 1,4 меңнән артык үзешчән артист катнашты. Барлыгы фестивальгә Татарстанның 43 районының 187 оешмасыннан гариза килгән.

Юбилей сезонының төп вакыйгасы булган гала-концертны ачу тантанасында, Рөстәм Миңнеханов катнашучыларны сәламләп, аларның республика предприятиеләрендә тырыш хезмәттә генә түгел, иҗатта да талантлы булуларын әйтте.

– Бүген без дәүләтебез өчен иң мөһиме хезмәт кешесе булуын аңлыйбыз. Заводларда, фабрикаларда һәм оешмаларда эшләүче кешеләр – илебезнең чын патриотлары. Хәзерге вакытта махсус хәрби операциягә мобилизацияләнүчеләрнең бер өлеше әзерлек уза, ә кемдер инде – хәрби хәрәкәтләр зонасында. Аларны азык-төлек белән тәэмин итүче предприятиеләрдән һәм заводлардан башка без бернәрсә дә эшли алмас идек. Без сезгә таянабыз һәм ышанабыз, – диде Татарстан Президенты.

Президент ассызыклаганча, елдан-ел фестиваль үсә, предприятие җитәкчеләреннән дә актив ярдәм күрсәтелә. «Бу фестиваль – республикабыз горурлыгы», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Фестивальнең генераль продюсеры Дмитрий Туманов әйтүенчә, илебез өчен катлаулы булган чорда республика корпорацияләре директорлары алдында һәр хезмәт кешесе өчен таяныч булу бурычы торган.

– Бу ният тормышка ашты. Татарстаныбызның күпмилләтле мәдәниятен саклау белән шөгыльләнүче һәр гаилә өчен зур бәхет бу. Башкаларга үрнәк булып торган татар мәдәниятенә зур рәхмәт, – диде ул журналистларга.

Гала-концертка кадәр өч сайлап алу этабы үткәрелде. Алар Әлмәт, Түбән Кама һәм Казанда узды. Финалга 46 оешмадан 650дән артык кеше чыкты. Инженерлар, укытучылар, балалар бакчалары тәрбиячеләре, табиблар, слесарьлар, полиция хезмәткәрләре, электриклар һәм башка һөнәр ияләре – Татарстан предприятиеләрендә һәм оешмаларында хезмәт куючылар бу кичтә үзләрен сәхнә артистлары ролендә сынап карадылар. 4 сәгать дәвамында барган тамашада «Музыкаль юнәлеш», «Дан минуты» һәм «Бию юнәлеше» номинацияләрендә 50дән артык концерт номеры күрсәтелде.

Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать институты ректоры Роза Әхмәдиева фестивальнең унъеллыгы Россия халыкларының мәдәни мирас һәм Татарстанда Цифрлаштыру елында узуының аерым әһәмияткә ия булуын билгеләп үтте.

– Мәдәниятне без бүген иҗади номерлар аша сәхнәдә күрдек, ә цифрлаштыру турында сөйләгәндә, бу конкурсны интернеттан бөтен ил карый, – диде ул.

Гала-концертта, чыннан да, милли колорит, халыклар дуслыгы рухы сизелде. Сәхнәдә республикабызда яшәүче милләт вәкилләренең җырлары яңгырады, татар, рус, мордва, чечен, болгар биюләрен күрергә мөмкин иде. Гомумән, театраль куелыш, күңелне күтәрә торган җырлар, дәртле биюләр тамашачыларны фестивальнең кабатланмас рухына чумдырды. Артистларның да ниндиләре бит әле, гади эшчеләр генә димәссең.

Эшче яшьләр иҗаты фестивалендә быел «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе командасы җиңү яулады. Алар Татарстан Президентының Күчмә кубогы, фестиваль иганәчеләреннән бүләкләр һәм 500 мең сумлык сертификат белән бүләкләнде. «Безнең заман герое» дигән махсус призны «КамАЗ» ачык акционерлык җәмгыяте командасы алды. Алар шулай ук кубок һәм 300 мең сумлык сертификат белән бүләкләнде.

Ләйсән САФИНА

Батырлар

Командир һәрвакыт алдан барырга тиеш

onf.ru

Руслан Корбанов, кабаттан махсус хәрби операциягә китәр алдыннан иң якын кешесен кочар өчен, Ставрополь краена әнисе янына кайтып килгән.

Командирга мондый зур һәм дәрәҗәле исем бирәләр икән, бу – беренче чиратта, аның кулы астындагы хәрбиләрнең уңышы. Күптән түгел Россия Герое исеменә лаек булган Руслан Корбанов әнә шулай ди. Казанның танк училищесын тәмамлаган, махсус хәрби операциядә үзен чын батыр буларак күрсәткән 26 яшьлек тыйнак егетнең тормыш сәхифәләрен барладык.

Руслан тумышы белән Дагыстан Республикасындагы Табасаранск районының Татиль авылыннан. 2006 елда алар гаиләләре белән Ставрополь краена күченәләр. 26 яшьлек батырның үсмерлек чоры Грачев районының Сергиев авылында уза. Ул чакта ук егет ирекле көрәш, самбо белән кызыксына. Буй җиткәч, Россиянең самбо буенча спорт остасына кандидат исеменә дә лаек була әле. Спорт кына түгел, алынган һәр эшен җиренә җиткереп башкарырга омтыла.

Мәктәпне алтын медальгә тәмамлап, 2014 елда Мәскәүнең югары гомумхәрби команда училищесына укырга керә, ә ике елдан аны Казанның югары танк команда училищесына күчерәләр. Бу уку йортын да ул иң яхшылар сафында тәмамлый.

– Казанда укыганда, үзен яхшы иптәш һәм көчле спортчы буларак күрсәтте. Горурлыгыбыз ул безнең! Танк училищесын тәмамлаган 13 егетебез, зур батырлык күрсәткәннәре өчен, Россия Герое исеменә лаек булды. Руслан – шуларның берсе, – диде безгә «Россия танкистлар берлеге» иҗтимагый хәрәкәте башкарма комитеты рәисе Альберт Гыймалетдинов.

Укуын тәмамлагач, Русланны Көнчыгыш хәрби округына җибәрәләр. Анда ул Тын океан флотының яр буе частьлары составына кергән аерым диңгез пехотасы бригадасында танк взводы командиры булып хезмәт итә. Бу елның 24 февраленнән махсус хәрби операциядә катнаша.

Кечкенәдән кыюлыгы, көчле рухы белән аерылып торган Руслан хәрби операциядә дә үзен батыр сугышчы итеп күрсәтә. Май аенда ул бер торак пунктны азат итүдә катнаша. Разведка һәм штурмлау төркемнәрен дошман ягына алып чыга. Шунда аның танкына һөҗүм итәләр, Руслан яралана, әмма кире чигенми. Экипажы дошман белән көрәшүен дәвам итә һәм алар мөһим позицияне кулга төшерә.

Соңрак лейтенант Корбановның взводына тагын бер зур бәрелештә катнашырга туры килә. Икенче танктагы экипаж контузия ала, аларга дошман кулына әсир төшү куркынычы яный. Руслан яраланган иптәшләренә ярдәмгә ашыга. Ул аларны үз танкына утыртып, тыныч урынга озата. Аннары, каршы як утка тотуга карамастан, туктап калган икенче танкны да безнекеләр ягына алып чыга.

Дүрт көн эчендә Руслан Корбановның танк взводы Украина кораллы көчләренең 38 берәмлек техникасын, шул исәптән 15 танкын һәм 2 миномет батареясын, 250ләп кешесен юк итә. Бу взвод шәхси составына кергән бер солдат та зыян күрми. Нәтиҗәдә торак пунктны дошманнан азат итәләр.

Күрсәткән батырлыклары өчен 26 яшьлек өлкән лейтенант Корбанов, Россия Президентының «ябык» Указы нигезендә, Россия Герое исеменә лаек була. Бу дәрәҗәле бүләкне ул Россия оборона министры Сергей Шойгу кулыннан ала. Министрлыкның социаль челтәрләрендә урнаштырылган видеода күкрәгенә «Алтын Йолдыз» таккан егетнең күзләрендә бәхет чаткылары күренсә дә, үзе ул бу батырлыгы өчен солдатларына рәхмәт укый.

– Гадәттә, көндәлек тормышта хәрби эшләр турында сөйләргә тырышмыйм. Ләкин бу турыда әти-әниемә әйтми булдыра алмадым. Сөенделәр, горурланабыз, диделәр. Үзем әллә ни зур хисләр кичермим. Командирга шундый зур һәм дәрәҗәле исем бирәләр икән, бу – беренче чиратта, аның шәхси составының уңышы. Без солдатларыбыз белән көчле. Хәзер инде кире хәрби операция зонасына, шәхси составым янына кайтам. Чөнки командир һәрвакыт алдан барырга тиеш, – дип сөйләгән Руслан Корбанов.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

ОЛТАН ТҮГЕЛ, СОЛТАН УЛ!

ТУГЫЗ ТЕЛ БЕЛҮЧЕ ХӘМИД ИРАНОВНЫҢ АВЫЛГА, ТЕЛГӘ МӘХӘББӘТЕ ТУРЫНДА

Чирмешән районының Бәркәтә авылында яшәүче терлек караучы Хәмид Иранов барысы 9 тел белә. Фермада эшләүче әлеге ир Көнчыгыш галиме түгелдер бит? Беренче мәлдә шундый уйлар туа. Юк, аны барына да тормыш өйрәткән.

22 ел элек Таҗикстаннан күченеп кайткан Ирановлар гаиләсенә Бәркәтәдә берәү дә кырын карамый. Беренчедән, үзләре дә тырыш: абзар тутырып мал асрыйлар. Эштә дә сынатмыйлар. «Чирмешәнагрохезмәтләре» җәмгыятенең Карамал бүлегендә хатыны Оркыя сыер сауса, Хәмид терлекләр карый. Ә инде көтү чыга башлагач, кара көзгә кадәр – табигатьтә. Унбиш елдан артык кулыннан чыбыркы төшми аның. Эшчән, тәртипле гаиләләрне кем яратмасын ди? Икенчедән, бу авыл аларга ят түгел. Хәмиднең әнисе Тәзкирә шушы авылныкы. Шуңа күрә авыл да, аның халкы да Ирановларга бик якын.

– Бәркәтәгә кайтканда, миңа 30 яшь иде. Башка туганнарым да Татарстанда яши. Энем – Әлмәттә. Ике сеңлем Чирмешән районында кияүдә. Исәннәрдән шулар. Әти-әни вафат инде. Әтидән төпчегебез нибары 7 көнлек булып калды, – ди Хәмид. – Элек, эш эзләп, Үзбәкстан, Таҗикстан якларына барсалар, хәзер, киресенчә, Татарстанга кайталар. Эшсез тору бик яман. Әни мәрхүмә авылга ике ел алданрак кайтып киткән иде. «Балам, эш булмаса, авылга кайт», – дип чакырды. Башта үзем кайттым, аннан гаилә белән төпләндек. Авылда кем генә булып эшләмәдем: моторист, шофер, шабашник, сыер савучы, ат җигүче, ферма мөдире… Эшләгән кешегә эш беркайчан да бетми.

Кызык, үзе гади һөнәр иясе булса да, шуның кадәр телне ничек өйрәнгән икән?

– Әтием – үзбәк, шуңа күрә үземне үзбәк дип саныйм. Татарча беләм, шөкер. Русчаны да су урынына эчәм. Азәрбайҗан, төрекмән, кыргыз, төрек, казах, таҗик телләрендә дә сөйләшә алам. Тагын нинди тел кирәк? Иранга барган юк, анысын белмим, – ди Хәмид әфәнде. – Төркия, Үзбәкстанда булдым, башка җирләрдә дә, – дип, ураган юлларын санап китте ул. – Кая барсаң да, анда яшәүчеләрнең телләрен өйрәнмичә булмый. Белмәсәң, син беркем түгел. Шул халыкның телен өйрәнеп, аралашып яшәргә кирәк. Һәрхәлдә, мин шулай иттем. Элек базар тирәсендә кайнаштым. Берәү дөге сатса, син карбыз, кавын сатасың, башкасын алып кайтасың. Шуның кадәр телне белүем юктан түгел, аралашу нәтиҗәсе. Хатыным, балаларым да татарча, үзбәкчә белә. Оныкларыбызга да туган телне өйрәттек.

cheremshan.tatarstan.ru

Читтә яшәсә дә, татар телен белә. Әнисенең татарча җырлаганын әле дә яхшы хәтерли. Авылдагы туганнары татарча журналларны посылка итеп сала торган булган. «Әни укыгач, без дә кызыгып укыдык. Хәзер шәһәргә барсаң, татарларның күбесе русча сөйләшә. Хастаханәгә, кибеткә керсәң дә, шул ук хәл. Татарларның үз телендә сөйләшмәвенә аптырап куям кайчак. Бу нинди хәл инде?» – ди ул.

– Шуның кадәр тел белгәч, сезгә галим генә буласы бар. Нигә көтү көтеп йөрергә дип, эшегезне алыштыру теләге тумадымы? – дип, кылларын тарткаладым әңгәмәдәшемнең.

– Яхшы эшләрдә дә эшләп караганым булды. Әйткәнемчә, элек тегендә-монда йөрергә туры килде. Яшь барган саен гаиләне беренче урынга куясың. Хатыным белән 32 ел яшибез. Өч кыз үстердек, алар кияүдә инде. Йортыбыз зур. Әле менә оныклар кунакка кайтты. Эш бар, гаиләм тыныч. Тагын ни кирәк? Менә шушы рәхәтлекне бернигә дә алыштырасы килми, – диде Хәмид, ниндидер бер горурлык белән.

Көтүче һөнәрен сайлаганга бер дә хурланмый, киресенчә, бу хезмәтне зурлап сөйли. «Теләсә кем көтүче була алмый, – ди. – Малларны карарга, күзәтергә кирәк. Төсләренә кадәр беләсең. Ашыймы, юкмы… Анысы да мөһим. Кайсы ялгыш суга төшә, кайсы бозаулый. Күбенгән сыерларны коткарган чаклар да булды. Гомумән, көтүче битараф була алмый. Иркенәйсәң, маллар як-якка таралышып бетәчәк. Яшьләр көтүче булып эшләргә теләми. Эшкә урнашалар да бер атнадан китәләр. Сабырлык кирәк. Өстеңә яңгыр явып торса да, көтүне ташлап китеп булмый. Челләсенә дә түзәсе. Холкың нык булу кирәк. Җыен 10 яшьлек оныгым Рамазан булыша.

Көтү көтеп баеп булмый, ди. Айга 30 мең сум тирәсе хезмәт хакы ала. Шунысына да бик риза ул. Колхоз көтүеннән әкренләп авылныкына күчтек. Авыл бик зур булса да, сыерны нибары унлап хуҗалыкта гына асрыйлар икән. Алары да электрон көтүчегә калган. Бу урында Хәмид сыерларның урам тутырып мөгрәп кайткан чакларын сагынып куйды: «Мал күп, авыл гөрләп тора, кызык иде. Хәзер алай түгел шул. Авылда яшьләр юк», – диде ул, көрсенеп.

Шул ук вакытта кәефе янә күтәрелеп китте. Бәркәтә авылының матур табигате, яхшы кешеләре турында мактап сөйли башлады. Сахраларда еш йөргәнгәме, күңеленә бар матурлык сыйган аның. «Урман кырыенда чикләвек җыясың, су буенда балык тотасың. Әгәр көтүең тыныч булса…» – ди. Тик туган ягы турында да сүз кузгатмыйча калып булмады.

– Авылда үзбәкләр бар, алар белән аралашып яшибез. Милли гореф-гадәтләрне дә саклыйбыз. Хатын ике ел элек туган якка барып кайтты. Илләр тыныч булса, быел бергәләшеп барырга исәп. Туган җир барыбер сагындыра, әмма анда барсаң, Бәркәтә искә төшә. Күңел менә шулай ике якта бәргәләнә, – диде ул, туган ягына мөнәсәбәтен белдереп.

Сәрия МИФТАХОВА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 6697 данә
Гомуми тираж – 15337 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 365

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+